| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районы**<br>**Әлмәт авыл җирлеге советы** |

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ<br>02 ноября 2024 года | КАРАР<br>№ 10 |

Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 18 маендагы 6 номерлы Әлмәт авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Әлмәт авыл җирлеге советы карар итте:

1.Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында» Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге Советы 6 номерлы 18 май 2020 елгы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 9 пунктындагы 6 пунктчасында "тапшыра" сүзеннән соң "түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча"сүзләрен өстәргә.;

2) 5 статьяның 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:: "- Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентын билгели;";
3) 9 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:: "туристлык салымы-100 процент норматив буенча.»;
2. Әлеге карарның 1 пунктның 2 пунктчасы 01.01.2025 елдан үз көченә керә..

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда әлеге карарны игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә. Газизов.